| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |

*423979, Р.Т. Муслюмовский район, с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная д.31а*
Vbash.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-07-20*

№ 2 — 2018 ел, 28 нче декабрь

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегендә 2019 елда бер тапкыр түләүне (үзара салым) оештыру һәм үзара салым акчалары тотыла торган төзекләндерү чаралары исемлеге турында**

Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы № 23-ТРЗ "Җирле референдум турындагы законы", Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 18 ноябрендәге 358 нче номерлы "Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында" карарына нигезләнеп, 2019 елда Вәрәшбаш авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлегендә 2019 елга бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен 18 яше тулып җирлектә яшәү урыны буенча теркәлгән, шулай ук теркәлмәгән , әмма муниципаль берәмлек территориясендә милке булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә расларга.
2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидларына, I, II төркем инвалидларына, ӘДР хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте аркасында инвалид калганнарга, нурлы авыру алган яки кичергән гражданнарга 500 (биш йөз) сум күләмендә түләүне билгеләргә.
3. Бер тапкыр түләү вакытын 2019 елның 1нче апреленә кадәр расларга.
4. Авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар буенча үзара салым акчаларын җыюны оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.
5. Үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга. (1нче кушымта)
6. Авыл җирлеге башкарма комитетына үзара салым акчаларын әлеге исемлек буенча тотарга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.
7. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Вәрәшбаш авыл җирлеге битендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/Vbash.htm.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз остендә калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы** **З.М.Маннапова**

Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш
авыл җирлеге башлыгы 2018 елның 28 декабрендә кабул ителгән
2нче санлы карарына 1 нче кушымта

**Вәрәшбаш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеге**

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
2. Халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
3. Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру;
4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;
5. Авыл җирлеге биләмәләрен төзекләндерүне оештыру;
6. Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү;
7. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
8. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
9. Авыл җирлеге биләмәсе чикләрендә халыкны эчәр су белән тәэмин итүне оештыру;
10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге юл эшчәнлеге;
11. Халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру;
12. Җирлекләрне территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
13. Сукбай хайваннарны тоту(аулау) һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру.

**Авыл җирлеге башлыгы: З.М.Маннапова**